ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ СӘРДӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

СОВЕТ ВЕРХНЕСЕРДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422015 Республика Татарстан Атнинский район с. Верхняя Серда. Тел. 3-28-70

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

«11» ноябрь 2019 ел.　　　　№ 2

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2019 елның 10 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты 24 ноябрь 2019 ел 13.00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;

- үткәрү урыны — Югары Сәрдә авылы, Үзәкурамы урамы, 21 йорт, Югары Сәрдә авылы клубы;

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 18 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Югары Сәрдә авылы, Татарстан урамы, 40 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Югары Сәрдә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Югары Сәрдә торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Авыл җирлеге биләмәсе территориясен чистарту тәртипләрен раслау, аларның үтәлешен тәэмин итү, территорияне төзекләндерүне билгеләнгән кагыйдәләргә таянып оештыру:

- Югары Сәрдә авылы территориясендәге агач һәм куакларны кисү, чистарту.

2. Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- Югары Сәрдә авыллы зираты территориясендәге агач һәм куакларны кисү, чистарту;

- Югары Сәрдә авыллы зираты коймасы өчен материалар алу.

3. Авыл җирлеге биләмәсе чикләрендәге автомобиль юлларын төзекләндерү эшләре:

- Югары Сәрдә авылы юлларыны түшәү өчен вак таш алу һәм транспорт өчен түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълумат-телекоммуникация челтәрендә тубәндаге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Югары Сәрдә авылы, Үзяк урамы, 21 йорттагы мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4.Әлеге карар ул халыкка игълан ителган көннән уз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Хуснутдинов